| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ОКТЯБРЬСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ОКТЯБРЬ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|

# КАРАР

19 ноябрь 2025 ел №135

**Хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында**

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгына таянып, хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында Октябрь авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Шуны билгеләргә:

- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге башкарма комитеты хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык вазыйфаи окладтан, компенсация түләүләреннән, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүләрдән һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрдән гыйбарәт;

- хезмәткәрнең вазыйфаи оклады күләме 8130 сум тәшкил итә.

2. Махсус климат шартлары булган урыннарда эшләгән өчен түләүләрне үз эченә алган компенсация түләүләре күләмен - хәрби-исәп хезмәткәренең район коэффицентын - 1,15 расларга.

3. Хәрби-учет хезмәткәрләренә билгеләргә:

3.1. Тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түбәндәге күләмнәрдә:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процентлар |
|---|---|
| 1 елдан артык | 5 |
| 2 елдан артык | 10 |
| 3 елдан артык | 15 |
| 5 елдан артык | 20 |
| 10 елдан артык | 30 |
| 15 елдан артык | 40 |

3.2. Вазыйфаи бурычларны намус белән үтәгән өчен календарь ел йомгаклары буенча ике вазыйфаи оклад күләмендә акчалата бүләкләү;

3.3. Билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр.

4. Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерына югарыда күрсәтелгән категориядәге хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фондын әлеге максатларга федераль бюджеттан бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә булдыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Зеленодольск районы, Октябрь Бистәсе. Беренче Май урамы, 2нче йорт, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Октябрь Бистәсе, Беренче Май ур., 5нче йорт.

Октябрь авыл җирлеге башлыгы М.В. Евдокимова

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1648018190
ОГРН 1061673003963